ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.04.2020 ел Баулы шәһәре №88

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 15 мартындагы «Административ комиссия салган административ штрафларны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләттерүне өметсез дип тану һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында»гы 67 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясына үзгәрешләр кертү турында»гы 2020 елның 7 апрелендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 15 мартындагы «Административ комиссия салган административ штрафлар буенча бурычларны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләттерүне өметсез дип тану һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында»гы 67 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Карарның резолютив өлешендә:

1нче пункттан соң түбәндәге эчтәлекле 2нче пункт өстәргә:

«2. Кушымтадагы Административ комиссия салган административ штрафлар буенча бурычларны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләттерүне өметсез дип тану һәм бетерү турында

документларны карау һәм карарлар кабул итү буенча комиссия составын расларга»;

2нче һәм 3нче пунктларны 3нче һәм 4нче пунктлар дип санарга.

1.2. Административ комиссия салган административ штрафлар буенча бурычларны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләттерүне өметсез дип тану һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибендә:

I бүлектә:

1.2. пунктында «таможня эше» сүзләрен «таможня җайга салуы» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлектә

2.1. пунктында:

б) пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«шәхси эшкуар булмаган гражданны банкрот дип тану өчен, «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә;»;

г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) хөкем ителгәннәргә карата штраф яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә җәзага карата амнистия яки ярлыкау турында актларны куллану, алар нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта;»;

түбәндәге эчтәлекле е) пунктчасын өстәргә:

«е) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм суд приставы-башкаручы тарафыннан, «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 ноябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1нче өлешенең 3нче яки 4нче пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә, башкару эшләрен тәмамлау турында элек чыгарылган

карарның булуы, - оешманың мөлкәте җитмәү һәм аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле түләнмәгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә. Теркәүче органның «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында»гы 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны Бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карарын карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, элегрәк әлеге пункт нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Тәртипнең 2.1 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, әгәр Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы кодексында билгеләнгән очракларда административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар чыгарылса, түләнмәгән административ штрафлар түләтүгә өметсез дип таныла.»

1.3. Әлеге карарга кушымта нигезендәге редакциядә кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://www.bavly.tatarstan.ru адрес буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
15 мартындагы 67 номерлы
карары белән
РАСЛАНГАН

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның _______________ _____
номерлы карары редакциясендә

Административ комиссия салган административ штрафлар буенча бурычларны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләттерүне өметсез дип тану һәм бетерү турында документларны карау һәм карарлар кабул итү буенча комиссия
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Гозәеров Ильяс Исмәгыйль улы | -Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Свежинкина Лилия Салихҗан кызы | - Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Осипова Азалия Салават кызы | - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе баш белгече-сәркатибе, комиссиянең җаваплы секретаре; |
| Каһиров Радик Әхмәтсафа улы | - Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы; |
| Шәрәфетдинова Лена Кирам кызы | - Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының керемнәр бүлеге начальнигы. |

________________